| | | |
|---|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ** |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**25.02.2020** г. Казань №**325**

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгының
ведомство бүләкләре турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 22 һәм 191 статьялары, 2004 елның 27 июленнән № 79-ФЗ «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында» Федераль законы, 2003 елның 16 гыйнварыннан № 3-ЗРТ «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законы, 2011 елның 23 декабреннән № 1052 «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы турында нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары белән расланган Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмә нигезендә, сәламәтлек саклау өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләрне, шулай ук сәламәтлек саклау тармагын үстерүдә һәм камилләштерүдә актив катнашкан башка затларны мотивацияләү һәм кызыксындыру системасын камилләштерү максатыннан б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының ведомство бүләкләрен гамәлгә куярга:

«Мактаулы остаз» аерымлылык билгесе;

«Татарстан Республикасының Мактаулы сәламәтлек саклау хезмәткәре» күкрәк билгесе;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Мактау грамотасы;

Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының Рәхмәте.

2. Теркәлеп бирелгән Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының ведомство бүләкләре турында нигезләмәне расларга.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының кадрлар бүлегенә әлеге боерыкның 2 пункты белән расланган Нигезләмәгә туры китереп эшне оештырырга.

4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының эшләр идарәчесенә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының

ведомство бүләкләре бланкларын, «Мактаулы остаз» аерымлылык билгесен, «Татарстан Республикасының Мактаулы сәламәтлек саклау хезмәткәре» күкрәк билгесен һәм аларга таныклыклар хәзерләүне тәэмин итәргә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Министр М.Н.Садыйков

25.02.2020 № 325
ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы
боерыгы белән расланган

# Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының ведомство бүләкләре турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының ведомство бүләкләренә (алга таба – ведомство бүләкләре, Министрлык) тәкъдим итү тәртибен, ведомство бүләкләрен тапшыру тәртибен һәм ведомство бүләкләре тасвирламасын билгели.

1.2. Ведомство бүләкләре әлеге нигезләмәдә күрсәтелгән сәламәтлек саклау өлкәсендә затларның казанышларын бүләкләү һәм иҗтимагый тану формасы булып тора.

1.3. Ведомство бүләкләре белән озак еллар намуслы хезмәте һәм күренекле казанышлары өчен, халыкның сәламәтлеген саклау, медицина ярдәменең сыйфатын һәм һәркем өчен мөмкин булуын күтәрүдәге казанышлары өчен, сәламәтлек саклау өлкәсен үстерүгә ярдәм итүче сәламәтлек саклау өлкәсе оешмаларының хезмәткәрләре һәм коллективлары, шул исәптән юридик зат оештырмыйча гына эшкуарлык эшчәнлеген башкаручы затлар, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының хезмәткәрләре һәм дәүләт гражданлык хезмәткәрләре, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка башкарма органнары хезмәткәрләре, эшчәнлекнең башка өлкәләре оешмалары хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау ветераннары бүләкләнә алалар.

1.4. Ведомство бүләге белән бүләкләү турындагы карар Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры (алга таба – министр) тарафыннан кабул ителә һәм Министрлык боерыгы белән рәсмиләштерелә.

1.5. Яңа казанышлар өчен ведомство бүләге белән бүләкләү алдагы бүләкләүдән соң ике елдан да иртәрәк була алмый.

1.6. Ведомство бүләгенең кабат шул ук төре белән бүләкләү башкарылмый.

1.7. Ведомство бүләге тантаналы шартларда министр тарафыннан яисә аның кушуы буенча башка вазыйфаи затлар тарафыннан бүләкләү турында Министрлык боерыгы бастырылганнан соң 3 айдан да соңга калмыйча тапшырыла.

1.8. Башка юридик затка хокуклар һәм вазыйфалар (функцияләр һәм вәкаләтләр) тапшыру белән оешманың (органның) ликвидациясе (юкка чыгарылуы) яисә үзгәртеп корылганы очрагында, бүләкләнүче кандидатның оешмада (органда)

эш (хезмәт) стажына таләпләренә туры килүе билгеләнгәндә, аның эш (хезмәт) стажы саклана һәм өзлексез булып санала.

1.9. Ведомство бүләге яки аңа таныклык югалган очракларда, Министрлык бүләкләү фактын раслаучы белешмә бирә. Ведомство бүләкләре дубликатлары бирелми.

1.10. Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасында эшләмәүче оешмаларга ведомство бүләге белән бүләкләү турында Министрлык боерыгы бастырылганнан соң 10 эш көне эчендә бүләкләү материалларының оригиналлары кире кайтарыла.

1.11. Бүләкләү материалларын Министрлыкка Татарстан Республикасы электрон документ әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы аша җибәргәндә бүләкләү материалларының оригиналларын тәкъдим итү таләп ителми.

## II. Ведомство бүләге белән бүләкләүгә тәкъдим итү нигезләре

2.1. Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының Рәхмәте (алга таба – министр Рәхмәте) намуслы хезмәте, сәламәтлек саклау системасын үстерүгә һәм камилләштерүгә керткән өлеше өчен әлеге Нигезләмәнең 1.3 пунктында күрсәтелгән затларга белдерелә. Сәламәтлек саклау өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренә министр Рәхмәтен белдерү сәламәтлек саклау өлкәсендә кимендә өч ел эш стажы булганда гамәлгә ашырыла.

2.2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Мактау грамотасы (алга таба – Мактау грамотасы) белән озак еллар намуслы хезмәте, эштәге уңышлары, Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын, сәламәтлек саклау белән идарә итү системасын үстерүгә керткән өлеше өчен әлеге Нигезләмәнең 1.3 пунктында күрсәтелгән затлар бүләкләнәләр. Мактау грамотасы белән сәламәтлек саклау өлкәсендә кимендә 10 ел эш стажы булган, шул исәптән соңгы эш урынында 3 ел эш стажы булган сәламәтлек саклау оешмалары хезмәткәрләре (юридик зат оештырмыйча гына эшкуарлык эшчәнлеген башкаручы затлардан тыш), моңа кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының Рәхмәт хаты белән бүләкләнгән затлар бүләкләнәләр.

2.3. «Татарстан Республикасының Мактаулы сәламәтлек саклау хезмәткәре» күкрәк билгесе (алга таба – күкрәк билгесе) һәм таныклыгы белән сәламәтлек саклау өлкәсендәге казанышлары булган һәм тармакның үсешенә зур өлеш керткән, намуслы һәм мактауга лаек хезмәтләре, һөнәри осталыклары, сәламәтлек саклау системасын үстерү һәм ныгыту, сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт программаларын тормышка ашыруда актив катнашу, сәламәтлек саклау өлкәсендәге проблемаларны хәл итүгә юнәлтелгән фәнни-нигезләнгән программаларны һәм

проектларны эшләп чыгару, сәламәтлек саклау өлкәсендә фән казанышларын һәм алдынгы тәҗрибә кертү, дәреслекләр һәм укыту-методик әдәбият, күргәзмә әсбаплар һәм җиһазлар булдыруда өлеш кертү, сәламәтлек саклауның актуаль проблемалары буенча фәнни тикшеренүләр уздыру, медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар белән нәтиҗәле хезмәттәшлек итү һәм аларга ярдәм күрсәтү өчен сәламәтлек саклау өлкәсе оешмалары хезмәткәрләре бүләкләнәләр.

Күкрәк билгесе белән сәламәтлек саклау өлкәсендә кимендә 10 ел хезмәт стажы булган, шул исәптән соңгы эш урынында биш ел эшләгән, моңа кадәр Мактау грамотасы белән бүләкләнгән хезмәткәрләр бүләкләнәләр.

Моңа кадәр Мактау грамотасы белән бүләкләнмәгән, әмма сәламәтлек саклау өлкәсендә 25 елдан артык стажы булган затлар шулай ук күкрәк билгесе белән бүләкләнәләр.

2.4. «Мактаулы остаз» ведомство аерымлылык билгесе (алга таба – Аерымлылык билгесе) «Остаз» исеменә кимендә 3 ел ия булган Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының югары квалификацияле дәүләт граждан хезмәтчәннәре һәм хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагында булган учреждениеләр хезмәткәрләре (алга таба – хезмәткәрләр, Министрлык, учреждениеләр) арасыннан яшьләрнең остазлары бүләкләнә торган ведомство бүләге булып тора.

Әлеге Нигезләмәдә остазлык эшчәнлеге астында аңлашыла:

яшь белгечләргә аларның һөнәри осталыкларында һөнәри белемнәрен, күнекмәләрен һәм өйрәнүләрен уңышлы үзләштерүдә ярдәм итү;

яшь белгечләргә хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартларына һөнәри һәм вазыйфаи җайлашуда, шулай ук вазыйфаи бурычларны үтәгәндә барлыкка килгән һөнәри кыенлыкларны җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү;

яшь белгечләрне индивидуаль эшләүнең һәм коллективта эшләүнең нәтиҗәле формаларына һәм алымнарына өйрәтү, вазыйфаи бурычларны мөстәкыйль һәм сыйфатлы башкару, үз һөнәри дәрәҗәсен күтәрү сәләтен үстерү.

Аерымлык билгесе белән хезмәткәрләр бер үк вакытта түбәндәге таләпләргә туры килгәндә бүләкләнәләр:

а) кимендә 10 ел сәламәтлек саклау өлкәсендә өзлексез эш стажы булу;

б) квалификация дәрәҗәсе (белем алу, квалификация күтәрү турында документлар), һөнәри казанышлары (һөнәри эшчәнлек, һөнәри осталык конкурсларында җиңүләре өчен бүләкләр һ. б.) булу; дисциплинар җәзалар булмау;

в) остазлык эшчәнлеген кимендә өч ел гамәлгә ашыру (актив һәм намуслы остазлык эшчәнлеге өчен бүләкләр булу; остазлык эшчәнлегенең уникаль практикалары (программалары) булу; остазга беркетелгән һөнәри казанышлары (квалификациянең раслануы, бүләкләр, аларның карьера үсеше) булу).

2.5. Ведомство бүләкләре белән бүләкләнүгә кандидатлар бер үк вакытта түбәндәге таләпләргә туры килергә тиешләр:

федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә алынмаган яки түләнмәгән хөкем ителү булмау;

алынмаган дисциплинар җәза булмау.

## III. Ведомство бүләге белән бүләкләүгә тәкъдим итү тәртибе

3.1. Ведомство бүләге белән бүләкләүгә тәкъдим итү турындагы карар хезмәт коллективы яки профсоюз оешмасы җыелышы тарафыннан бүләкләүгә тәкъдим ителә торган затның төп эш урыны буенча, ветераннарны бүләкләгәндә – ветераннарның иҗтимагый оешмасы тарафыннан кабул ителә.

Ведомство бүләге төре бүләкләүгә тәкъдим ителә торган затның казанышлары дәрәҗәсен, характерын һәм әлеге нигезләмәне исәпкә алып билгеләнә.

Юридик зат оештырмыйча гына эшкуарлык эшчәнлеген башкаручы затны ведомство бүләге белән бүләкләү турындагы үтенечнамә әлеге зат тарафыннан Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры исеменә мөстәкыйль рәвештә тапшырыла.

3.2. Бер үк вакытта берничә кандидатураны бүләкләүгә тәкъдим иткәндә гариза гомуми исемлек белән оформить ителә.

3.3. Ведомство бүләге белән бүләкләү турындагы үтенечнамәгә түбәндәге документлар теркәлә:

тәкъдим итү (№ 1 кушымта);

кандидат паспортының 2,3 бите күчермәсе;

кандидатның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык;

хезмәт коллективы (профсоюз оешмасы) яки ветераннар иҗтимагый оешмасының вәкаләтле органы җыелышының протоколы;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау учреждениеләрендә остазлыкны үстерү буенча Татарстан Республикасы Медицина хезмәткәрләре ассоциациясе каршындагы Иҗтимагый совет җыелышының протоколы («Мактаулы остаз» ведомство аерымлылык билгесе өчен).

Министрлык карамагындагы оешма җитәкчесен, Министрлыкның дәүләт граждан хезмәтчәнен һәм хезмәткәрен бүләкләүгә тәкъдим иткәндә үтенечнамәгә һәм тәкъдим итүгә әлеге юнәлешне алып баручы министр урынбасары тарафыннан кул куела.

Рәхмәт белән бүләкләү турындагы үтенечнамәгә (коллектив өчен) теркәлеп бирелә:

тәкъдим итү (№ 2 кушымта);

учреждениенең тарихи-архив белешмәсе;

үтенечнамә белән мөрәҗәгать итү датасына кадәр бер айдан да соңга калмыйча Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан алынган өземтә;

юридик затның дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе,

гамәлгә кую документының (уставның яисә нигезләмәнең) 1, 2 битенең күчермәсе;

оешманың (органның) хезмәт хакы, салымнар һәм җыемнар буенча бурычлары булмавы турында белешмә.

коллективның казанышларын раслаучы документлар.

3.4. Министрлык карамагындагы оешмалар үз хезмәткәрләрен, шул исәптән үз филиаллары хезмәткәрләрен бүләкләү турындагы документларны үзләре урнашкан урын буенча Министрлыкның территориаль органы белән килешкәннән соң Министрлыкка җибәрәләр.

Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасында эшләүче оешмалар бүләкләү материалларын әлеге системада тапшыралар.

3.5. Бүләкләү турында документлар кергән көннән алып 30 көн эчендә Министрлык кандидатны ведомство бүләге белән бүләкләү яисә бүләкләүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Билгеләнгән таләпләрне бозып тапшырылган яки кандидатлар әлеге нигезләмәдә күрсәтелгән таләпләргә туры килмәгән очракта бүләкләү турындагы документлар 30 көнлек срок белән кире кайтару сәбәпләрен нигезләү белән кире кайтарылырга тиеш. Бүләкләү турындагы документлар кисәтүләрне бетергәннән соң кабат кертелергә мөмкин.

3.6. Күкрәк билгесе белән бүләкләнүче сәламәтлек саклау хезмәткәренең намусын һәм абруен төшерүче җинаять кылган өчен күкрәк билгесеннән мәхрүм ителергә мөмкин. Хезмәткәрне күкрәк билгесеннән мәхрүм итү, күкрәк билгесен мәхрүм итү мотивларын нигезләп, сайланган профсоюз органы һәм оешманың (органның) хезмәт коллективы белән килештерелгән оешма (орган) җитәкчесе тәкъдиме буенча министр боерыгы белән башкарыла. Күкрәк билгесе таныклык белән бергә Министрлыкның кадрлар бүлегенә кире кайтарылырга тиеш.

## IV. Ведомство бүләкләре тасвирламасы

4.1. Ведомство аерымлылык билгесе һәм таныклык – «Мактаулы остаз» (№ 3 кушымта);

4.2. «Татарстан Республикасының Мактаулы сәламәтлек саклау хезмәткәре» күкрәк билгесе һәм таныклыгы (№ 4 кушымта);

4.3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Мактау грамотасы (№ 5 кушымта);

4.4. Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының Рәхмәте – А4 форматы (№ 6 кушымта).

4.5. Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының Рәхмәте – оешмалар коллективлары өчен А3 форматы (№ 7 кушымта).

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау
министрлыгының
ведомство бүләкләре
турында нигезләмәгә
№ 1 кушымта

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының
ведомство бүләкләре белән бүләкләүгә
ТӘКЪДИМ ИТҮ

1. Фамилия, исеме, әтисенең исеме (булган очракта) ___________________________

2. Туу датасы______________________________________________________________

3. Эш урыны, били торган вазыйфасы: _______________________________________

4. Белеме (нинди уку йортын һәм кайсы елда тәмамлаган, белгечлеге): _______________________________________________________________________

5. Квалификация категориясе (булган очракта): ________________________________

6. Хезмәт стажы (еллар): 1) гомуми__________2) сәламәтлек саклау өлкәсендә________3) әлеге коллективта __________4) остаз буларак____________

7. Бирелгән бүләкләре (бүләкләү турында боерыкның датасы һәм номеры):__________________________________________________________________

8. Хезмәт эшчәнлеге:

| Ае һәм елы | | Органны яки оешманы күрсәтеп вазыйфа | Орган яки оешма урнашкан урын |
|---|---|---|---|
| керүнең | китүнең | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

9. Тору урыны адресы, контакт телефоны: _______________________________

10. Оешманың (профсоюз оешмасының) хезмәт коллективы җыелышының протоколы яки бүләкләү турында үтенечнамә кузгаткан ветераннар иҗтимагый оешмасының вәкаләтле органының карары номеры һәм датасы:______________________________________________________________

11. Алынмаган яки түләнмәгән хөкем ителү булу:__________________________

12. Алынмаган дисциплинар җәза булу:__________________________________

13. Характеристика (конкрет казанышлар):_______________________________

Җитәкче (вазыйфасы күрсәтелә)

_________________ / _______________________
имза имза расшифровкасы

М.У. (булган очракта)

Хезмәт коллективы җыелышы рәисе яки профсоюз оешмасы рәисе яки ветераннар иҗтимагый оешмасы вәкаләтле заты

_______________/________________________________
имза имза расшифровкасы

«Килештерелгән»:

Сәламәтлек саклау идарәсе башлыгы_____________

_________________________/__________________________________
имза имза расшифровкасы

***Тәкъдим итүне тутырганда нинди дә булса кыскартулар, аббревиатуралар, төгәлсезлекләр, төзәтүләр рөхсәт ителми***

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау
министрлыгының
ведомство бүләкләре
турында нигезләмәгә
№ 2 кушымта

Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының
Рәхмәте белән бүләкләүгә
ТӘКЪДИМ ИТҮ (коллектив өчен)

1. Коллективы бүләкләүгә тәкъдим ителгән оешманың атамасы:
_______________________________________________________________
(нигезләмә, органның, оешманың оештыру документлары нигезендә татар һәм рус телләрендә тутырыла)
_______________________________________________________________
2. Коллективы бүләкләүгә тәкъдим ителгән оешма эшчәнлегенең төп төре (төрләре)
_______________________________________________________________
3. Оештырылу датасы: ____________________________________________
4. Оешма коллективында булган дәүләт бүләкләре төрләре:________________
_______________________________________________________________
5. Оешманың урнашу урыны адресы, контакт телефоны:____________________
6. Коллективы бүләкләүгә тәкъдим ителгән оешманың характеристикасы
_______________________________________________________________
Татарстан Республикасы алдындагы казанышларны күрсәтеп, ирекле формада тутырыла

Җитәкче (вазыйфасы күрсәтелә)
_________________ / _______________________
имза имза расшифровкасы
М.У. (булган очракта)

Хезмәт коллективы җыелышы рәисе яки профсоюз оешмасы рәисе яки башка вәкаләтле зат
_______________/______________________________
имза имза расшифровкасы

«Килештерелгән»:
Сәламәтлек саклау идарәсе башлыгы_____________
_________________________/_________________________________
имза имза расшифровкасы

***Тәкъдим итүне тутырганда нинди дә булса кыскартулар, аббревиатуралар, төгәлсезлекләр, төзәтүләр рөхсәт ителми***

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау
министрлыгының
ведомство бүлекләре
турында нигезләмәгә
№ 3 кушымта

«Мактаулы остаз» ведомство аерымлылык билгесенең тасвирламасы







Билге 32 мм диаметрлы соры төстәге металлдан (көмеш шикелле) түгәрәк медальдән гыйбарәт.

Медальнең алдынгы ягының үзәгендә медицина эмблемасы – касәнең аягын урап, касә өстеннән башын июче елан сурәтләнгән. Эмблема күләмле, рельефлы, көмеш төстә. Билгенең тышкы әйләнәсе буенча «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы» дигән көмеш төстәге рельефлы язу урнашкан. Медицина эмблемасы астында көмеш төстәге «ОСТАЗ» дигән көмеш төстәге рельефлы язу, (киңлеге17,6 мм, биеклеге 2,9 мм) урнашкан.


Билгенең арткы ягында рельефлы язу: «Мактаулы остаз» һәм аерымлылык билгесенең номеры.

Билге бөҗра ярдәмендә бант салынган тасма белән тоташтырыла.

Тасма ефәк, кырые буенча көмеш каймалы кызыл төстә. Тасманың киңлеге – 24 мм, көмеш кайма киңлеге – 2 мм. Каймадан тасма кырыена кадәр ераклык – 2 мм.

«Мактаулы остаз» аерымлылык билгесе күкрәкнең уң ягында киеп йөртелә.

«Мактаулы остаз» ведомство аерымлылык билгесе таныклыгының тасвирламасы




Таныклык 100 Х 65 мм үлчәмле куе кызыл төстәге бумвинилдан тышланган китаптан гыйбарәт.

Таныклык тышлыгының алгы ягының үзәгендә шелкография белән 25 мм диаметрлы Татарстан Республикасының Дәүләт гербы сурәте, аның өстендә татар телендә 10,5 үлчәмле шрифт, язма хәрефләр белән язылган «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ» дигән язу ясала. Аның астында рус телендә 10,5 шрифт, язма хәрефләр белән язылган «МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» дигән язу ясала.

Таныклыкның эчке сул һәм уң ягында (борылышында) тангир сеткасы (яшел яки алсу) фонында рус һәм татар телләрендә текст белән вкладыш бланкы ябыштырыла. Вкладыштагы язулар югары сыйфатлы басма принтерда үтәлергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау
министрлыгының
ведомство бүләкләре
турында нигезләмәгә
№ 4 кушымта

**«Татарстан Республикасының Мактаулы сәламәтлек саклау хезмәткәре» таныклыгы**








Таныклык 100 X 65 мм үлчәмле куе кызыл төстәге бумвинилдан тышланган китаптан гыйбарәт. Таныклык тышлыгының алгы ягының үзәгендә шелкография белән 25 мм диаметрлы Татарстан Республикасының Дәүләт гербы сурәте, аның өстендә татар телендә 10,5 үлчәмле шрифт, язма хәрефләр белән язылган «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ» дигән язу ясала. Аның астында рус телендә 10,5 шрифт, язма хәрефләр белән язылган «МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» дигән язу ясала.

Таныклыкның эчке сул һәм уң ягында (борылышында) тангир сеткасы (яшел яки алсу) фонында текст белән (сул якта татар телендә, уң якта рус телендә) вкладыш бланкы ябыштырыла. Вкладыштагы язулар югары сыйфатлы басма принтерда үтәлергә тиеш.






**«Татарстан Республикасының Мактаулы сәламәтлек саклау хезмәткәре» күкрәк билгесенең тасвирламасы**

«Татарстан Республикасының Мактаулы сәламәтлек саклау хезмәткәре» күкрәк билгесе эмальле томпактан ясала, үзара бөҗралар белән тоташтырылган ике өлештән тора.

Өске өлеше 26*15 мм кызыл төстәге турыпочмак формасында, аның астында – алтын төстәге кабарынкы яфраклар.

Аскы өлеше 40 мм диаметрлы түгәрәк формасында. Түгәрәк билгенең өстендә ак төстәге елан белән касә сурәтләнгән, үзәгендә – кызыл фонда ике телдә (рус һәм татар) «Мактаулы хезмәткәр» дигән ак төстәге язу, әйләнә буенча – алтын төстәге имән яфраклары.

Күкрәк билгесенең номеры юк. Өске өлешнең арткы ягында кием-салымга билгене беркетү өчен булавка урнашкан.

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгының
ведомство бүләкләре
турында нигезләмәгә
№ 5 кушымта

*Пример использования*




*Пример построения*




**Үлчәме:**
210 Х 297 мм (формат А4).

**Материал:**
картон Gemini тибы, ак төстә, тыгызлыгы 220 г/кв.м.

**Басма технологиясе:**
тулы төсле басма.

**Төсе:** 4+0 (CMYK), басу алтын фольга белән.

**«Язу» блогы:**
басу алтын фольга белән
шрифт Times New Roman Bold,
кегль: 14 п.,
интерлиньяж: 15 п.,
язу ике телдә
язма хәрефләр белән башкарыла,
үзәк буенча тигезләү.

**«Мактаулы грамота» блогы:**
басу алтын фольга белән,
шрифт Times New Roman Bold,
кегль: 50 п.,
язу язма хәрефләр белән башкарыла,
үзәк буенча тигезләү.

**«Казан» блогы:**
шрифт Times New Roman Regular,
кегль: 12 п.,
язу язма хәрефләр белән башкарыла,
үзәк буенча тигезләү.

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгының
ведомство бүләкләре
турында нигезләмәгә
№ 6 кушымта

*Пример использования*




*Пример построения*




**Үлчәме:**
210 Х 297 мм (формат А4).

**Материал:**
кәгазь Colotech тибы, ак төстә, тыгызлыгы 250 г/кв.м.

**Басма технологиясе:**
тулы төсле басма.

**Төсе:** 4+0 (CMYK).

**«Язу» блогы:**
шрифт Times New Roman Bold,
кегль: 14 п.,
интерлиньяж: 15 п.,
язу ике телдә язма хәрефләр белән башкарыла, үзәк буенча тигезләү.

**«Рәхмәт» блогы:**
шрифт Times New Roman Bold,
кегль: 45 п.,
язу язма хәрефләр белән башкарыла,
үзәк буенча тигезләү.

**«Имза» блогы:**
шрифт TimesNewRomanBold,
кегль: 14 п.,
интерлиньяж: 19 п.,
блокларны тигезләү уң һәм сул як буенча.


**«Казан» блогы:**
шрифт Times New Roman Bold,
кегль: 12 п.,
үзәк буенча тигезләү.

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгының
ведомство бүләкләре
турында нигезләмәгә
№ 7 кушымта

*Пример использования*




*Пример построения*



**Үлчәме:**
297 X 420 мм  (формат А3).

**Материал:**
кәгазь Colotech тибы, ак төстә, тыгызлыгы 250 г/кв.м.

**Басма технологиясе:** тулы төсле басма.

**Төсе:**4+0 (CMYK).

**«Язу» блогы:**
шрифт Times New Roman Bold,
кегль: 40 п.,
язу ике телдә язма хәрефләр белән башкарыла,
үзәк буенча тигезләү;

шрифт Times New Roman Bold,
кегль: 18 п.,
интерлиньяж: 25 п.,
язу ике телдә язма хәрефләр белән башкарыла,
үзәк буенча тигезләү;

**«Имза» блогы:**
ике телдә башкарыла;
шрифт Times New Roman Bold,
кегль: 14 п.,
интерлиньяж: 19 п.,
блокларны тигезләү уң һәм сул як буенча.

**«Казан» блогы:**
ике телдә башкарыла;
шрифт Times New Roman Bold Italic,
кегль: 14 п.,
интерлиньяж: 19 п.,
блокларны тигезләү уң һәм сул як буенча.